ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.12.2018 г. Заинск № 1908

**"Гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында гражданнар керемнең һәм мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү турында»**

Гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларга муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында, 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьясы, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Югарыда күрсәтелгән законны гамәлгә ашыру максатларында 2019 елга Зәй муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрына 26 695,81 сум күләмендә уртача базар бәясен расларга., Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 4 декабрендә кабул ителгән 1778 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрына уртача базар бәясен исәпләү методикасы нигезендә исәпләнгән.
2. 2019 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган мөлкәтнең иң чик кыйммәтен расларга. (1 нче кушымта)
3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.
4. Торакларны исәпкә алу һәм бүлү бүлегенә гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә кую вакытында 1нче кушымтада күрсәтелгән иң чик күрсәткечләрен кулланырга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

М.М. Хабибуллин
3 13 37

Н.Г.Павлова
7 07 75

Зәй муниципаль районы Башкарма
комитетының 2018 елның
25 декабрендәге 1908 номерлы
карарына1 нче кушымта

**Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләме һәм 2019 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының иң чик күләме.**

| Гаилә әгъзалары саны | Гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган мөлкәт хакының иң чик күләме (сум).) | Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме (сум.) |
|---|---|---|
| 1 | 880 961,7 | 21 839,01 |
| 2 | 1 121 224,0 | 13 897,54 |
| 3 | 1 441 573,7 | 11 912,19 |
| 4 | 1 922 098,3 | 11 912,19 |
| 5 | 2 402 622,9 | 11 912,19 |
| 6 | 2 883 147,5 | 11 912,19 |
| 7 | 3 363 672,1 | 11 912,19 |
| 8 | 3 844 196,6 | 11 912,19 |
| 9 | 4 324 721,2 | 11 912,19 |
| 10 | 4 805 245,8 | 11 912,19 |